**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Татар Димскәе авыл җирлеге" муниципаль берәмлек составына керүче Райлан авылындагы гражданнар җыены карары**

**2024 елның 09 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Татар Димскәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Райлан авылы торак пунктындагы гражданнар җыены нигезендә карар кылды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Татар Димскәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Райлан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , күп балалы гаиләләрдән тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Райлан авылында чишмәне төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**"Татар Димскәе авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлек башлыгы** **Л. Ә. Хәбирова**